СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**« 13 » июль 2022 ел** **№ 159**

**Арча муниципаль районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе турында**

«Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» 2011 елның 20 маендагы 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кертелгән үзгәрешләргә бәйле рәвештә, Арча район Советы карар бирде:

1. Арча муниципаль районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе составын расларга (1 нче кушымта).

2. «Арча муниципаль районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе турында» Арча район Советының 2014 елның 05 апрелендәге 260 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. «Арча муниципаль районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе турында» 2014 елның 5 апрелендәге 260 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Арча район Советының 2014 елның 6 маендагы 269 номерлы карарын үз көчен югалткан дип санарга (22.01.2015 №315, 28.05.2015 №337, 12.08.2015 №351, 10.11.2015 №16, 07.04.2016 №51, 12.06.2016 №56, 14.12.2016 № 96, 27.09.2017 №144, 16.05.2018 №182, 31.10.2018 №234, 16.10.2020 №18, 02.02.2021 №44, 12.11.2021 №95, 26.05.2022 №153.1 үзгәрешләр белән).

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http:arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча район Советының законлылык, җәмәгать тәртибен саклау һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
Арча район Советы рәисе И.Г.Нуриев

Арча район Советының
"13" июль 2022 ел, № 159
карарына 1 нче кушымта

**Арча муниципаль районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе**
**СОСТАВЫ**

| | |
|---|---|
| Вафина Эльвира Шамилевна | - Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, комиссия рәисе; |
| Мөхәмәдияров Рамил Данилович | - Арча муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф идарәсе» МУ башлыгы, рәис урынбасары; |
| Шакирова Миләүшә Ниязовна | - Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Арча муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы, рәис урынбасары (килешү буенча); |
| Хәкимҗанова Альбина Фәритовна | - Арча муниципаль районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең җаваплы секретаре, комиссия секретаре; |
| ***Комиссия әгъзалары:*** | |
| Кузнецова Алсу Альбертовна | - «Арча үзәк район хастаханәсе» ДАССУ балалар консультациясе мөдире (килешү буенча); |
| Яруллина Рафия Гомәровна | - Арча муниципаль районы Башкарма комитеты аппаратының опека һәм попечительлек бүлеге башлыгы; |
| Ильина Лия Юрьевна | - Арча муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф идарәсе» МУ башлыгы урынбасары; |
| Гайнетдинов Фәнил Фәһимович | - Россия Эчке эшләр министрлыгының Арча районы буенча бүлеге полиция башлыгы урынбасары (килешү буенча); |
| Дәүләтшина Нурсөя Ринатовна | - ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Мәрхәмәтлелек үзәге» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесендә ОСПСиД мөдире (килешү буенча); |
| Сәмиева Наилә Рәисовна | - Арча муниципаль районында бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил (килешү буенча); |

| | |
|---|---|
| Гыйбадуллина Гөлфия Мансуровна | - Арча муниципаль районының «Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ директоры (килешү буенча); |
| Хәбиров Айрат Фиркатович | - Арча муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгы; |
| Борһанов Алмаз Әгъзамович | - Арча һәм Әтнә районы буенча хәрби комиссар (килешү буенча); |
| Хәбирова Рамилә Гомәровна | - Арча муниципаль районы Башкарма комитетының әйдәп баручы белгече; |
| Гатауллина Әлмирә Мидхәтовна | - Арча муниципаль районының хатын-кызлар советы рәисе (килешү буенча); |
| Әюпов Илфар Илдарович | - Арча муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәдәният идарәсе» МУ башлыгы. |